ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2020 г. Заинск № 244

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында нигезләмәне раслау хакында»**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләренә ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт

законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә контроль буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле шартларны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http//zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының http//pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

С.Н. Веселов
7 10 27